Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

# КАРАР № XXII-4

Балык Бистәсе штп. 2022 елның 31 мае

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 маддәсе, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсе нигезендә, муниципаль берәмлекнең тотрыклы үсеше, муниципаль берәмлек территориясен планлаштыру өчен шартлар тудыру максатларында, инвестицияләрне җәлеп итү, шул исәптән җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән файдалануның иң нәтиҗәле төрләрен сайлап алу мөмкинлеге бирү юлы белән дә, әйләнә-тирә мохитне һәм мәдәни мирас объектларын саклау, физик һәм юридик затларның, шул исәптән җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларына хокукый ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатларында, 2002 елның 14 апрелендә үткәрелгән ачык тыңлауларның нәтиҗәләрен игътибарга алып, "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең кушымта итеп бирелә торган Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен расларга.

2. Көчен югалткан дип танырга:

- "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 июнендәге 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Зур Мәшләк авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турынд" гы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 31.03.20021 ел, № IX-11 карарын;

- "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 июнендәге 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Зур Мәшләк авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" гы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 13.11.20021 ел, № XIV-5 карарын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Зур Мәшләк авылы, Үзәк урам, 20 нче йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль

районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов